

*Марат Закир*

# *Кояшлы төн*



***Шигырьләр***

*Казан*
*Татарстан китап нәшрияты*
*2005*

УДК 820/89(470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
З 19

**Закир Марат**

З 19 Кояшлы төн: Шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 79 б.

Әлеге китапка авторның төрле елларда иҗат иткән лирик-фәлсәфи һәм балалар өчен язылган шигырьләре тупланды.

ISBN 5-298-04100-0
© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Марат Закир, 2005



*Әнием Халидә (Миңнегөл) Бикмулла кызы Гайнуллинанаң якты истәлегенә багышлыйм.*

*Автор*



# I

Ап-ак ташлар...
Аунап ятасыз —
Элеккедәй бөек түгел сез.
Ни эзли бу егет, дисезме? —
Йөзе моңлы,
Үзе күңелсез...

# Ватан

Манаралы мәчет ак булган —
Бабамнарның изге мөнбәре.
Килдем менә бүген сәҗдәгә,
Изгеләргә соң мин кем әле?

Ап-ак ташлар...
Аунап ятасыз —
Элеккедәй бөек түгел сез.
Ни эзли бу егет, дисезме? —
Йөзе моңлы,
Үзе күңелсез...

Манарадан калган бу ташлар,
Туфрагы да шуннан — ярмалы.
Көмеш айны һаман аулый шул
Күктә кара болыт кәрваны.

Баш сөяген алам кулыма —
Бабайлардан калган шөһрәтме?
Манарадан калган бу ташлар
Бүген миңа, бәлки, эндәшер:

— Шушы изге газиз туфракка
Төкергәндә залим һай-һайлап,
Каберләрне нәҗесләгәндә,
Кайда идең, олан, кайларда?
Кайда идең, олан, кайларда?

# Караңгылык

...Күрәп алырлык, күрәп алырлык
Күрәгең булса — караңгылык.

Дөм караңгы тарафлар...
Әллә бу
Алла каһәрләгән якмы соң?
Коры хыял сыман тыпырчына
Еактагы йолдыз яктысы.

Якты күтә кавем ничә гасыр —
Хәттин ашкан мәнсез сабырлык.
Бу кавемнең мәнсез сабырлыгы
Җенне хәтта егып салырлык.

Мәрткә киткән илнең күзен беркөн
Караңгыдай кара кан баса.
Килә! —
Җитә! —
Сыта! —
Кара язмыш,
Чакма чагар затың калмаса.

Кара таңнан кара төнгәчә ул
Кара тиргә батып бил бөгә.
Кемдер аны каулый караңгыдан —
Арттан кага кемдер дилбегә.

Бүлгәләргә теләп бу кавемне
Төрле яктан аңа кем дәшә? —
Әрле-бирле йөри караңгыда,
Корбан эзләп йөри каһкаһә...

Бүлгәләргә теләп, кара затлар
Аны йөртә упкын тирәли.
Нигә бу кавемгә караңгыда
Тавык күзле күзнең кирәге?!

Бүлгәләргә теләп, кара җаннар
Бутап куйган аның кыйбласын.
Адаштырмас юлга тартыр затың,
Чакма чагар затың кайда соң?!

Сыңар очкын җитәр иде, бәлки,
Киптерергә канлы күз яшен.
Әмма күрәчәген бик шәп күрә:
Белә кавем гүргә керәсен.

Кара янып көйгән бу кавемне
Кара хөкем, кара үч баскан.
Каһәр суккан мәлгунь караңгыны
Озатырга иде, ичмасам —

Бармы караңгыны тансыклаган,
Бармы җирдә шундый бер халык?!
Ыргытырга иде көрәп алып, —
Тик...
Көрәп алып ыргытырлык
Көрәге юк шул, көрәге юк...

* * *

Урыс каены, диләр. Урыс каены.

Ниһаять, мин дә күрдем аны: кала уртасындагы җимерек өйләр арасында — тишек гөмбәзле чиркәү, шул чиркәү гөмбәзеннән тортеп чыккан да үсеп утыра кәкре-бөкре бер каен. Әмма дә туфрагы барыбер татардан: бу урында кайчандыр мәһабәт мәчет торган...

## Бәһа

Һәрнәрсәнең бәһасе бар!
Һәрнәрсәнең бәһасе бар!
Килер бер көн — бәһаләргә
Заман үзе бәһа куяр. —
Заман үзе бәһа сугар!
Бәһасен белгәнче генә
Сатылмыйча тора тауар...

* * *

Базар читендә бер карт —
Ап-ак кәфендәй бер карт —
Юмарт кына елмая:
«Сатам!
Хакы да — юк хак...

Гомер буе тупладым,
Алыгыз, хәләл малым:
Хаталарымны сатам,
Алтындай хаталарым...»

## Хәер соранучы

Йа Хода! —
Кыш-кыска кул сузган икмәкне
Алыр өчен дә, кара:
Никадәрле озын икән бит,
Озын икән бит... ара.

# Капка төбендә

Яфрак кебек коела көннәр, коела көннәр... Ә өйдә мәңгелек белән бәхәсләшә мич артындагы чикерткә...

Нигә икән бу җанга мең елга җитәрлек, бушанмаслык сагыш иңгән... Нигә икән?!

Бөгәрләнгән гәзит диярсең: бөгәрләнеп бетте яктылык. Аннары «иртәгә, бәлки әле, төшәрмен дә» дигән сыман гына, сабыр атлап, тирәк яфракларына баса-баса, баскыч буйлап югарыга менеп китте яктылык.

Эңгер-меңгер... Бабайларның гына башы — якты-ак.

# Ирек

Ачып чыгардылар кенәрине читлегеннән иркен залга. Әмма талпынды ул ирек өрәге артыннан иксез-чиксез дөньясына! Һәм... Бәрелеп үлде тәрәзә пыяласына...

Буламыни ярым-йорты ирек — йә бар ул, йә юк. Бәхет сыман, сөю сыман ул — йә бар, йә юк!

Язмыш каршында — Татар иле... Ә ирек?

# Бер ачыш

Сынганчы гына,
Сынганчы гына
Дәһшәтле икән
Сөңге очы да...

# Китап

Бер иманың булса җанында,
Кирәкми яңарту мең кабат —
Һәр аятеннән бу Китапның
Иңнәренә иңә мең канат!

Шуңа күрә дә иртәләрен,
Көндезләрен һәм дә кичләрен
Китап укый баглап әбекәй
Күңелендәге изге хисләрен.

Нур иңә Китаптан әбигә.
Бу нурдан хәтта өй җылынган.
Иң садә халәте әбинең:
Бу нурдан керфеге чыланган...

# Ишелгән мич

Җиде көймәле урыс миченең идәнгә ишелде кирпечләре. Аптырашта кирпечләр: соң, кем тезгән иде безне, без нишләдек?!

Төтенгә буылган тәмуг көннәренең үткәненә инану мөмкинме? Мичче кулы кирпеч түгел, гүя мең көнгә тоташтырган мең көнне...

Кемгә ничектер, кирпечләргә менә сизелде, һай, сизелде-е-е вакытларның узганы.

...Түрдәге сурәтен мичче картның вак тузан сарды — вакыт тузаны.

# Татар тормышы

Бер тарафтан бер тарафка җил уңаена таралышып агып бара гамьсез болытлар...

Көлә-көлә көләч ал таңда чалгы җырын тыңлый үләннәр...

Төшләрендә балта-пычкы күреп, шомланышып шаулый имәннәр...

Шулай яшәгәннәр. Шулай яшәделәр... Оныклар да шулай яшәрме?

# Фәрештә

*Яшьли вафат булган әниемнең якты истәлегенә*

Коръән язуыдай изге сырлар иңгән иде аның күз төшләренә. Коръән битләре сыман иде куллары да ул фәрештәнең.

Рөхсәт итә иде ул безгә гел канатларын алып торырга. Һәм без күтәрелә идек ул канатларда йолдызларга — югарыга!

Әй шатлана иде ул, энем белән минем болытларда мәтәлчек атканны күреп. Карын ачкач, без дә кайта идек әзер табынга җилкенеп. Без биектә-биектә кичергәнне бер-беребезне бүлдерә-бүлдерә сөйләгәндә, йотлыгып-йотлыгып тыңлый иде ул тын гына, сыйпый-сыйпый өстәл ашъяулыгын. Әмма без аңламый идек, әле без аңламый идек шул безнең өчен бу дөньяның сүздән түгел, синнән башланганын.

Беркайчан да сөйләмәде үзе, бахыр, канатларының каян килүен сөйләмәде. Сөйләмәде беркайчан да — без йоклаганда, безне калдырып, ни өчен күккә күтәрелмәвен — сөйләмәде...

Сизенгәнсеңдер. Сизенгәнсеңдер... Очып калсыннар! дигәнсеңдер...

# Мөһажир

Биектә лә, аһ, биектә
Аккошларның кәрваны.
Чыңлап тора бу илдә дә
Җырлары вә моң-зары.

Бара-бара тоныкланыр
Зарларың, әй, ак кәрван:
Күкнең кауры болытлары
Калмас сезнең артлардан.

Ни эзлисез кара төндә,
Кайда сезнең оягыз?
Юк кәрваным,
Юк канатым —
Калам инде мин ялгыз.

Кемне, кемне чакырасыз
Кара төндә, аккошлар?
Калам инде мин чарасыз,
Калам инде, аһ, кошлар...

Кошларым, озаккамы мин
Туган җирдән еракка?
Очсагыз да үпкәләмим —
Сынау язган ир-атка.

Мөлдер-мөлдер мөлдерәмә
Яшьне тыю — мөхаль* тик.
Егылырмын кайтыш мин дә:
— Туган җирем, нихәл? — дип...

* Мөхаль — мөмкин түгел.

# Нократ

(*Мәдхия*)

Халкым сыман сабыр булдың,
Һәй, Нократ — Көмеш елгам!
Гасырларның төпкелендә —
Син кичкән озын юллар.

Ил телендә — Көмеш елга,
Кем телендә — башкача...
Үткәннәрен онытканның
Туган телен таш баса.

Телне дә, әйе, таш баса,
Әгәр ятса ил йоклап.
Саф килеш сакла суыңны,
Җегәрле бул, һәй, Нократ!

Сабырлыкның чиге чыга,
Зилзиләләр башланса.
Ярларыннан кубар Нократ,
Чишмәләрен таш басса.

Безнең йөрәкләр янганда,
Сыкрап, сыкрап, һәй, сыктап,
Дулкын кагар ярсып-ташып
Чулман, Идел вә Нократ.

Килер әле безгә дә бер
Иманлы, гадел шөһрәт!
Типсеннәр гаярь чишмәләр,
Мең яшә син, һәй, Нократ!

Бул син мәңге-мәңгелеккә
Көзгесе — якты вә пакь —
Мамадыш дигән төбәкнең,
Һәй, Көмеш елгам — Нократ!
Һәй, Көмеш елгам — Нократ!

# Дусай жыры

*(Җыр)*

Кемгә дә газиз, кадерле
Туган авыл, туган нигез.
Көннәр, айлар, гомер үтә —
Һәркем була монда тигез.

К у ш ы м т а:
Агыш бара еллар
Шыя суларыдай.
Алыш кайта юллар
Сиңа бары, Дусай!

Әйтерсең лә гасыр аша
Ерак бабам үзе дәшә:
— Кеше булыш яшә, балам,
Нәсел җебең өзелмәсен!

К у ш ы м т а.

Кара болытка баш бирмәс
Манарадагы бу аең.
Кара болыттан саклар ул
Балаларыңны, Дусаем!

К у ш ы м т а.


Х.Л.



# II

...Ага дәрья ташлар аша,
Бәргәләнеп ярсу көйгә.
Бу дәрьяның уртасында
Тыпырчына бәллүр көймә,
Тыпырчына бәллүр көймә.

# Кояшлы төн

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар?..

*Дәрдемәнд*

Кемне көтәсең, минеме —
Чатырыңда — кемне, төн?
Ярым-йорты булсам көндез,
Төннәрдә мин — гел бөтен...

Ике күзем яна минем —
Әйтерсең лә ябалак!
Залим көннең җансыз нуры
Ташлый мине яралап...

Төнлә генә бөтен шул мин —
Кичалсам төксе көнне...
Төн-әнкәм бул үксезеңә,
Җәлләмә тик сөтеңне.

Олы төнгә барган чакта,
Синдә яшти сабыең.
Синнән башка инде янә
Кемгә, төнем, сыеныйм?!

Синнән башка инде янә
Кемгә, төнем, табыныйм?!
Синнән башка, якты төнем,
Кемгә барыйм тагын мин?!

Кара дулкын толымыңны
Ташла, төнем, таратып!
Садә, серле кояш синең
Күзләреңнән тама күк.

Хәтерләтеп көннең дә бит
Дөньяда барлыгыннан
Якты ут яна тибрәнеп,
Тетрәнеп карыныңда.

Залим көннәр мәхшәрендә
Адашып йөргән җаным
Синдә генә таба үзен,
Синдә генә — маягым.

Төнем, төнем, газиз төнем,
Син минем бердәнберем!
Кальбем минем сиңа тугры,
Кояшлы, якты төнем!

Каләмем дә тугры кала
Каударланмыйча гына! —
Карыныннан авырттырып
Ал таң яралганчыга...

## Кышкы халәт

Тышта — кыш, диләр.
Ә мин ышанмыйм.
Язгы киңлеккә,
Назга очам мин.

Канатларым да
Йолкынган үзе.
Ак каурыйлары
Тышта ни эзли?

Очалмагач әгәр,
Нигә соң канат?
Ат син аларны,
Ат йолыккалап!

Безләргә очу…
Көмеш дөньясын,
Каурыйларым хет
Кар булып яусын.

Керфеген тапсын
Пакьләрдән пакьнең —
Урамнан барган
Сөйкемле затның.

Чылансын күзе
Ул гүзәл затның.
Бу халәттә мин
Пакьләрдән пакьмен.

Хәл-халәтем шул —
Гөтенсез морҗам.
Бу халәттә мин —
Нәзберек бер җан.

Кыш — кыш икәнен
Үзем дә беләм.
Назны көмде кыш
Карлары белән.

Тышта — кыш, диләр.
Һаман ышанмыйм.
Бу халәттә тик
Назга очам мин.

## Буранда

### 1

Синең дә кышың житәр, жаным,
Күбәләк бит сиңа буласы.
Әле синең дә бардыр иң әүвәл
Шушы бураннардай дуласың.

Кем аңламый, шуларга — сәер,
Бул әле буранның тылмачы.
Күбеккә баткан аргамакның
Уйлама тынасын — тыңлачы!

Салма шом күңелгә — тыңлачы!
Тыңлачы, әй, жаным, тыңлачы! —
Булганчы гомерлек мүкле таш,
Бер көнлек ак буран булсаңчы!

### 2

Дугасын ташлап чапкан аттай,
Аргамактай бит ул, һай, буран...
Аякларым тышауланмаган —
Нигә диеп әле кайгырам?!

Эндәшә миңа Төн-Алиһә,
Кагыла да килеп жиңемә:
«Кар башына карлар житкәнне,
Рәнжетерләр инде сине дә.

Юлдашларың әгәр алдаса,
Сиземләвең сине алдамас:
Аңламас сине кардәшләрең,
Һәм беркем дә инде аңламас...»

## Биеклек

Сүземнең чиштем бәен —
Һичнигә карамадым.
Үрләде аралап ул
Вак куак араларын.

— Син әле, имән, бик яшь... —
Куаклардан биектә
Имәнне сукты яшен.
— Кара күмергә калгач,
Ничек инде мин дәшим —
Дәшмим, дәшмим, дәшмим, дәш...

— Биегрәк, димәк, көчле, —
Дигән кеше кая ул?
Биегрәк булган саен,
Арта гына кыйналу...

Биегрәк булган саен,
Биегәя күкләр дә.
Башларың әйләнердәй —
Туктап калсаң бер мәлгә...

Аһ, бу сихри биеклек!
Биеклектә — җир яме!
Алыштыра башка буын
Яшен орган имәнне...

## Ят күл

Нинди якты, пакь көзге —
Күлгә бактым таң калып!
Үзе — көзге,
Үзе — күл? —
Ни бер тап юк, ни... балык.

# Мамык дивар

## 1

Сөйләдем кайгыларымны —
Елмаялар төркем-төркем.
Шатлыгымны чиштем сезгә...
Чиштем — тыңламады беркем.

Бәгыремне ачкан килеш
Үтте шулай бер көн... Мең көн!
Хәтта җансыз таш та болай
Бер чәрдәкләнергә мөмкин.

Хәтта җансыз таш та болай
Парә-парә кисәр үзен!
Мамык дивар гына исә
Пәрәнҗәгә кумәр йөзен...

## 2

Җырлап үттем сезнең яннан,
Җылап үттем, сүгенеп үтәм...
Ишетмәде мамык дивар! —
Әйтмәс булдым сүзне бүтән.

Әй, бичара-битарафлар,
Әйтмәм сезгә сүзне бүтән!
Әйтерсең лә кала тулы,
Кала тулы — күзле бүкән.

Бу дөньяда үлемнән дә
Җан өшеткеч тагын ни бар? —
Тупыл мамыгыдай йомшак
Салкын кардан салкын дивар!

— Нишлисең син, җүләр?! — диеп,
Бармы берәү кызыксынган?
— Дөрләтергә бу диварны,
Ут төртергә шырпы сызам...

## Матурлык

### 1

Затлы итеп бизәлгән биек сәхнәгә гади генә киенгән бер кыз бала чыгып басты. Башта ул шигырь сөйләде, аннары ул җыры белән аларның күңелен ачарга тырышты. Залда утыручы түрәләрнең, яңа байларның кашы җыерылды:

— Кая матурлык? Кая монда, в натуре, матурлык?!

Аның күңеле түгелде.

Үзен танымаганнарына Матурлык гаепле түгел иде...

### 2

Тагын да затлырак сәхнә түрендә (менә бу — да-а, ичмасам!) — җем-җем кызыл күлмәге! — Тыпыр-тыпыр биш баса! — Иреннәре тәмләп татырлык! — Күчмә Кызыл байрак шикелле, кулдан-кулга китте Матурлык...

# Энемә

...Урам чатындагы тупыллар да
Мамыгын тиздән коя башлар.
Күкләргә кадәр ашасы чакта
Кәүсәгә сеңгән ябалдашлар...

Язылган язулар балкып тора
Урам ханәләре кашында:
«Бер генә минутка тукталып кал,
Бер генә минутка ашыкма!»

Кемнәрдер әнә туктап калганның
Чырагына шычрак су салган...
Басалмас шикелле сыра гына,
Сыра гына безне сусаудан.

Китик моннан, энем, китик әйдә!
Безнең күңел, әйе, сусаган!
Менгән чакта, энем, биек тауга,
Табасы бер чара сусаудан.

Шәрә ботлар калсын шәраб уртлап,
Майлы күзләр шуны ботарлап.
Монда түгел, энем, безнең урын —
Биек тауда җәйри ак карлар!

Мажаралар эзләп үз башына,
Төнге җилләр кая ашыга?
Китик моннан, энем, китик әйдә —
Биек таулар көтә каршыда!

Китик моннан, энем, китик әйдә!
Йөк күтәреп тауга менгәндә,
Бер генә минутка тукталган да
Егылган, ди, әнә бер бәндә...

Бер генә минутка тукталган да
Кәүсәгә сеңгән ябалдашлар.
Әй талпына таш бина каршында
Башлары кыркылган агачлар...

Калкып тора башсыз агачларның
Мескенлектән гайре нәрсәсе?!
Шул агачлар сыман яшь кемдер
Күләгәнең булып шәүләсе.

Китик моннан, энем, китик әйдә —
Менгән чакта тауга, күр, әнә:
Күтәрелгән саен югарыга —
Өстән аска төшә күләгә!

Монда — сазлык.
Моннан китик әйдә —
Монда мескен тупыл зары бар.
Аяк терәр нокта эзләп, болар
Гомре буе тыпырчынырлар.

Сазлык затымыни безнең кавем?!
Анда әле тауның чыңы бар!
Без менәсе тауның әле алда
Бик нәни бер кыйшылчыгы ла...

Язылган язулар шунда калсын —
Урам ханәләре каршында:
«Бер генә минутка туктал, — имеш, —
Бер генә минутка ашыкма...»

Китик моннан, энем, китик әйдә —
Йөк күтәреп тауга менгәндә,
Бер генә минутка тукталган да
Егылган, ди, әнә бер бәндә...

## Көзге манзара

Шәмдәй каеннарга кояш
Ялкын үрләтеп мәш килә...
Әйтерсең лә көя төште
Урманның алтын шәленә —

Сыдырды да көяз җилкәй
Шәлнең бер күзәнәгеннән,
Хушлашты урман сулкылдап,
Хушлашты көзге ямь белән.

* * *

Ачыргаланып аваз салды
Өзелеп төшкән каен яфрагы.
Егыласыңны белеп егылулар
Авырдыр ул... авыр, ахры.

Йолдызларга үрелгән чаклар
Мизгел генә икән ләбаса!
Нинди вакыт бу?! Колагыңнан
Югарыга тарта, йә — баса...

Нинди вакыт бу?! Дөнья куып
Чиксез киңлек җиткән бер мәлдә
Биләп алыр да сары сагыш,
Селкеп салыр дымлы җирләргә...

Сабыры беткән көзге җилнең
Салкын карашы да — битараф.
Яшь аралаш яфрак елмая:
Җил — җил бит ул, аңа ни караш?

Какса да, сукса да, җил бит ул —
Табигать әмерен үтәүче.
Яфрак кебек җаным аркылы
Күпме җилләр әле үтәсе…

# Ташландык йорт

## 1

Ява да ява яңгыр
Сызылып та сызылып.
Ява да ява һаман —
Тегәрҗептәй сузылып.

Яңгырга каршы төндә
Яран гөл чәчәк аткан.
Ташландык йортның күзен
Шуңа яңгыр чылаткан.

Бу йортта, бу яңгырда
Бар да мин үзем, юк та —
Барыбер түгелмени
Күптән ташланган йортка?

Барыбер түгелмени
Күктән койган яңгырга?
Чыланасың чыланса,
Яндырасын яндырсаң...

Карап тора текәлеп
Кемдер кара чоланнан:
Чыланасын яндырдың,
Яндырасың — чыланган...

...Тәрәзне үпте яңгыр,
Күзен йомды яран гөл.
Үткәнне вакыт үпкән —
Калса калсын, ярар, көл...

Үткәннәр — баксаң, күптән
Ташланган йорт учагы.
Учак көлендә генә
Бу йортның җылы чагы...

Учак көлендә генә
Саркый һаман ул көннәр.
Ул көннәрем үткәнгә
Үкенмәм мин, үкенмәм.

...Яңгырлар үтте явып,
Нәүмиз калды яран гөл...
Тегәрҗеп белән генә
Тегәрлек яра түгел...

## Ялгыз яфрак

«Уятам», — дип, мәгърур күлне
Очып төште алтын яфрак.
Тирән күлнең көмеш суы
Тирә-ягын алды урап.

— Юк дулкының, суың тонык... —
Әй кычкырды аңа яфрак.
Бер чайкалды, бер талпынды
Тозак күлдән ул дау сорап.

— Ни дисәң дә, — дип көлде күл, —
Шул күлнең лә син иркендә.
Ялгызларга — бел! — һичкайчан
Ярдәм итмәс беркем дә!

...Гамьсез күлдә янды сыкрап
Сары яфрак — ялгыз ялкын...
Дөрли, бахыр, соңгы тапкыр,
Сулары да, ай-һай, салкын...

# Яшел яфрак җыры

Сокландыра мине яшеннәрнең
Яра-телә күкне яшьнәве.
Ярасын җирнең мин каплармын...
Тик
Яшеннәрдәй бит мин яшь әле!

Тарта мине күккә алтын нурлар,
Тамырлардан миңа тибә көч.
Болын үләне түгел — моңлы-боек,
Яшеннәре, җиле — миңа иш!

Куркытмагыз: килер, диеп, көзләр...
Яз шатлыгы — яшел яфракта!
Сары сагыш булып өзелеп җиргә
Төшәр көннәр әле еракта.

Тамчыларың татлы ширбәт сыман,
Яу, яңгыр,
          әй, яңгыр,
                    яусаңчы!
Чабуыннан, җилкәй, тарт болытның!
Яучы, яңгыр,
          там син,
                    әй, тамчы!

Кем генә синнән гайре әйдәсен —
Камчыла болытны, әй, яшен!
Тәкәббер болыт! Инде хәзер син
Тамчылар булыпмы төшәсең?!

— Җитте җәйләр, килер көзләр, — димсез, —
Яме җәйнең — җете яфракта!
Сары сагыш сыман өзелеп җирдә
Ятар көнгә әле ерак ла...

* * *

...Əллə нилəр кирəк сыман
Бу адəм баласына.
Барысы да сынау ласа,
Сынау юкса барысы да.

Сыгылмый ул, сыгылмаса.
Сыгылмый... сына гына.
Сына икəн, түзалмыйча
Дөньяның сынавына.

Агы, күге, карасы да —
Бер адəм баласына.
Өметлəнеп яши, бахыр,
Умырып аласына.

Азның азы кирəк сыман
Бу адəм баласына.
Кала бары шул кирəкне,
Кала... табасы гына...

## Түрə — түбə

Үсə барган саен һаман
Биегəя түшəме.
Түбəннəргə «түбə» булу —
Түрə өчен иң шəбе!

## Акча колы

Акча дигəн шайтанга
Жанын саткан бəндə лə...
Шайтаны да əнə бит
Янында ук əйлəнə.

## Бәллүр көймә

Ага дәрья ташлар аша
Бәргәләнеп ярсу көйгә.
Бу дәрьяның уртасында
Тыпырчына бәллүр көймә,
Тыпырчына бәллүр көймә.

Оча дәрья ташлар аша
Сөңге булып бәгырькәйгә.
Сөңге сынгач, таш ватарга
Бардыр, бәлки, бер-бер хәйлә,
Бардыр, бәлки, бер-бер кәйлә? —
Башын вата бәллүр көймә...

Гөрли-гөрли шаша, үрли,
Кадый дәрья ташлар аша!
Тамчы булып бәгырькәйдән
Тама нидер, тама ласа...

Ага дәрья ташлар аша
Бәргәләнеп ярсу көйгә.
Инде ничә еллар үтте? —
Кичеп кара бәрелмичә! —
Үрсәләнә бәллүр көймә...

## Замана

Зоопаркта язу:
«Бу — бер башлы бөркет».
Мутантлар заманы! —
Калдыгызмы өркеп —
Илдә канат җилпи
Ике башлы бөркет...

## Уян!

...Һай, ай-һай,
Татлы да соң йокы...
— Уян! —
Яңгыратып төчкерде таң, —
Исәнлеккә бу! — күрерсең,
Олы Төнгә өлгерерсең,
Уян, дускай, тор син, тор син!

Вакыт аты кешни анда.
Вакыт аты,
Вакыт аты!
Солы сыман сибелеп кала
Асыл көннәр бер-бер артлы...

* * *

...Яратылуын яратылганбыз:
Шәрә килеп шәрә китәсе...
Әмма килә икән фанилыкның
Шәрабыннан авыз итәсе:

Бер тутый кош — тутык тавышлымы? —
Читлегеннән тышка ашкына.
Ашкынма син, кошкай, туңарсың бит —
Бәйрәм итә анда кыш кына.

Ашыкма син, тутый, ташланырга
Таш каланың салкын карына:
Язлар түгел, зәмһәрир зат хуҗа
Бүген Казан урамнарына.

Тутык тавышлы, и тутый кошым,
Шупыңдамы синең торагың?!
Төпсез чәркәләрнең һәркайсына
Кора монда бәла тозагын...

Төпсез Җәмшид касәсеннән* дәме
Төпсез чәркәле бу хәрчәүнә?! —
Үзе белгән ләхәүләсен укыр
Хәрчәүнәдән чыккан һәр шәүлә...

«Туктап калган могҗизаи мизгел»
Төпсез чәркәләрдә ләбаса!
Ләм-мим дәшми карап торсаң, тәмләп,
Ләззәти бер рәхәт ләм баса...

...Хозыр Ильяс белән култыклашып
Чыгып бара кызый, йа Ходам!
Татлы шәраб сыман елмаюы
Арындырды мине йокыдан.

Әмма йоталмадым елмаюын:
Төер тыгылды бугазыма, зар.
Каба калса җанга ялкын әгәр,
Дары сыман коры бүген кар.

## «Юмарт» язмыш

Кайчагында «юмарт» язмыш килә:
Иртәле дә кичәле генә —
Капшык ярым шатлыгын бирәүгә
Бирә ул бик тә үлчәп кенә —
Бер кашык сагыш исәбенә.

Кайчагында килә миңа да ул —
Иртәле дә кичәле генә.
Сагыш исәбе генә бүтән:
Кемгәдер ул кашыклап эчертә,
Миңа менә — чиләге белән...

* Җәмшид касәсе — риваятьләр буенча бу савытның төбендә бөтен җир йөзе, тереклек чагылган.

# Качкын

...Авыл халкы эзли чыккан:
— Кайда икән, кайда үгез?
Көтүеннән качкан бүген
Моңсу күзле кара үгез.

Сагыш иңгән җан иясе,
Таза муен, сыньк мөгез —
Булса булыр япа-ялгыз
Тирә-юньдә мондый үгез.

Чаба! — Гүя баскан үгез
Җитез җилнең канатына! —
Каян сизгән, бахыр, диген:
Кичкә — ит комбинатына...

Болын буйлап чаба үгез.
Арттан килә вәкарь давыл:
Пычак сыман үткен дә ул,
Учак кебек кайнар да ул...

Туктап калды кинәт бахыр —
Карап-карап торды да ул,
Тезен чүкте бу нигәдер —
Тынды җилләр, тынды давыл...

Кызыл яулык болгый икән
Кызыл шәлле миләш кызы!
Карап тора үгез аңа —
Әйтерсең лә киңәш сорый.





## III

Тик безгә дип кенә китергән
Бу төндә җәйге җил яңгырны.
Бу төндә телгәләп мең кабат
Күбәләк канатын яндырды.

## Ашкынып чак

Әйди безне алга юллар —
Алга икән алга бак!
Бездә генә, бездә генә —
Җилдәй җитез аргамак!

Җилдәй исеп үтәр гомер —
Ашыгып кал, ашкынып!
Янса янсын яшь чагында
Без яшьләргә яшел ут.
Янса янсын яшь чагында
Яшь егеткә яшел ут!

Ниләр көтә безне алда —
Томан сарган юлларда?
Томан сарган юллардан да
Серлерәге юк анда.

Ниләр көтә безне алда —
Таулардагы карлы боз?!
Карлы боздан бара-бара,
Бәхеткәйне яуларбыз!

## Телефон

...Син — ул ярда, мин — бу ярда
Калдык хисләр кочагында.
Күңел юатырга бер сүз,
Бер сүз җитми кайчагында.

Син — ул ярда, мин — бу ярда...
Ярларны ярга ялгарга
Әле дә ярый, әле дә ярый
Тылсымлы телефон бар ла...

## Миләүшә

Мин кайттым, кайттым, Миләүшә!
Яз кошы әйдә сайрасын!
Куш каен да безне көткән,
Син генә кайда, кайда син?!

Югалттым, диеп, сине мин
Сабыштым чиргә сагыштан.
Тик таптым синең җырыңны
Талинештәге тавышта.

Күзләреңнең садә нуры
Чагылды көмеш чишмәдә.
Ник качтың үзең, Миләүшә,
Әйтче, зинһар, әйтче, нигә?!

...Хәбәр алып килде җилләр
Шау-шулы шәһәр ягыннан.
Сары шәлен, сары шәлен
Куш каен гына... ябынган...

## Мәхәббәтем

Яшен булып яшьни мәгыйшәтем.
Яшеннәрнең яше — бер мизгел.
Мизгел икән гомер, бу җирдәге
Хәятымнан инде мин биздем.

## Әллә ничек кенә...

Әллә ничек кенә — айлы төндә
Чәчәк аткан иде яран.
Әллә ничек кенә — шуннан бирле
Ярым булып калдың, Ярам.

Әллә ничек кенә — серле көздә
Таныштырды язмыш безне.
Әллә ничек кенә — язмыш үзе
Кавыштырды ялгыш безне.

Әллә ничек кенә — төштә микән,
Өндә булды микән ул чак?
Әллә ничек кенә... татлы газап! —
Янды дөрләп, янды учак!

Әллә ничек кенә — сәер көйгә
Үтеп бара безнең гомер.
Яшенле көннәрнең ялкыныннан
Калды бары, калды... күмер.

* * *

Минем шатлык синең шатлык булалмады,
Синең кайгың минем кайгым булалмады.
Бүлалмадык бер алманы, бүлалмадык...
Белалмадык бүлү серен, белалмадык.

Булалмадык,
        бүлалмадык,
                белалмадык...
Минем шатлык синең шатлык булыр иде,
Синең кайгың минем кайгым булыр иде —
Корт тишкән икән, баксаң, әй, ул алманы...

# Талчыбык

## 1

...Иелгән ярына Талинешнең
Иртән искән җилдән талчыбык.
Карлыгандай чем-кара күзләрең
Кемне көтә болай талчыгып?

Ярларга оя уя карлыгач.
Бу ярлар — ак бозлар кискән яр.
Булалмас инде, булалмас
Киткән бозлар сиңа хөкемдар.

Зарыгып көткән иде Талинеш
Яр карлыгачының кайтуын.
Ярлыкаучы сине гөнаһыңнан
Карлыгач түгел шул, һай, түгел...

## 2

Иелгән ярына Талинешнең
Иртән искән җилдән талчыбык.
Аны көтеп талган күзләреңдә
Әллә яшьләр, әллә таң чыгы...

Агасылар әле алда, диеп
Аккан суның төбе уемлы.
Җилләр сыга, кага сулармы
Талчыбыктай сылу буеңны?

Җилләр ни талчыбыкка, сулар ни —
Назлар кирәк аңа нибары.
Үбәр инде яшьле күзләреңнән
Талтирәкнең сары яфрагы...

## Кышкы сөю

Янар учак-сөюемне
Аңламавың сүндерде.
Көлләрен күмде бураннар,
Бәс сарды күңелемне.

Аңламадың сөюемне,
Аңламадың ул чакта.
Ник аттың кар йомарламын
Яныш торган учакка?

Учагымның ялкыныннан
Күзләреңме чагылган?
Тамар әле яшьләрең бер
Япа-ялгыз чагыңда...

Япа-ялгыз чакларың да
Үтмәс димә, үтәр лә.
Тагын килер ак бураннар
Толымнарың сүтәргә...

## Төнге этюд

Төнбоектай болытларның
Таҗларына кырын яткан —
Ураган төпсез галәмне
Нурларыннан ай һәр яклап.

Шушы илаһи диңгездә
Ымсындырып йөзә Зөһрә...
Бу тоткын кызына дипме,
Картлач Ай йолдызлар сөзә.

* * *

Көз — кызлар күңеле төсле,
Бер елмая, бер — төксе.

# Юрау

— Юрыймчы, бәгърем, бәхетеңне,
Күз багып йолдызларга.
— Юк-юк, тиеш бит мин үзем
Бәхеткә юл салырга!

— Юл күрсәткән борынгыдан
Йолдызлар юлсызларга...
— Ышанулар шул бик кыен
Синдәй гүзәл кызларга.

— Ышан, бәгърем. Аһ, китмә син
Ят җиргә тиң эзләргә.
— Корабым бит әзер инде
Чыгарга диңгезләргә.

— Йолдыз...
Китмә, бәгърем, китсәң —
Корабың адашыр юлсыз...
— Юк!
Кирәкми!
Үзем юрыйм! —
Күзләрең — ике йолдыз!

* * *

...Ашыктыра алсу җиләк:
— Тизрәк, тизрәк, әй, тизрәк!
— Печәннәрем оча җилгә —
Җайлап салыр җай сирәк...

Ак күлмәкле алсу җиләк
(Булса була ымсыну)!
Кирәк шәйдер дә бит үзе
Бу сылуга буйсыну.

Болытларга аша башым
(Булса булыр очыну)!
Җиләк ае түгел юкса —
Җәйнең кибән очы бу...

Аның да берзаман (көтәм)
Толымнары сүтелер.
Кибән очыннан бу җиләк
Болыт-күлгә сикерер.

Болыт-күлгә сикерер дә
Төнбоектай су керер.
Шунда гына төнбоектан
Назлы нурлар сирпелер...

Инде җәйнең кибән очы —
Җиләк ае, их, үткән...
Ашыктыра алсу җиләк:
— Яңгыр килә — төш күктән!

Үтеп китте болыты да,
Очланды ла кибәне.
Хәтерләтеп торыр инде
Кипкән җиләкнең тәме...

# Төнлә су керүче кызга

...Яктырды сине күргәч
Инеш яры.
Дулкынын какты инеш
Сиңа бары.

Йотты вөҗүд корабын
(Йә, оч, җаным!)
Ике айлы бер Бермуд
Өчпочмагы!

Бер күзле еланны да
Йотса икән!
Чумды егет инешкә —
Тик сай икән...

Сүнмәс назлы алтын сын,
Көләч сылу!
Көнләштем шашып-шашып
Көмеш судан.

Чык судан!
Чык судан!
Җир нурга тулсын!
Чәчкәең синең үзе —
Көмеш дулкын!

Төш күргән инешне син
Ник уяттың?
Башым, ахры, җен кызы,
Аһ, югалттым...

Басып торам тавышсыз.
Сүзсез. Ләм-мим.
Сайла берсен...
        Каршыңда —
Инеш һәм мин.

## Сыңар канат

Йорт каршында бакчада
Кортлы алма коела.
Ниләр генә керми лә
Ялгызларның уена...
Ялгызларның уена...

Төннәр кичеп, исәр җил
Шакып чыга ишекне.
Алмалар гына менә
Җилле җәйне иш итми.

Ничек итеп чишәргә
Мең төенле уйларны?
Оныттырырга телиме
Ак чәчәкле туйларны?

Кортлы алма коела,
Кортлы алма коела
Җәй башында бакчада,
Бакчадагы коега...

Мөлдерәмә сары төс
Саркый торгач түгелгән
Тирән кое төбедәй
Сагыш тулы күңелдән.

Ниләр генә алыр да
Салыр янә кайгыга? —
Тирән кое төбеннән
Карый хәзер ай гына...

Йорт каршында бакчада
Кортлы алма коела.
Җәй башында көз керә
Ялгызларның уена.

Ятсынма, җил, уз түрдән!
Сызла, йөрәк, сызла син!
Язмышлар гына инде
Караларын сызмасын.

Язмышларның карасын
Ияртмә, йөрәк, син дә:
Үч атлы үрмәкүчнең
Эләкмә ятьмәсенә!

Пар канатның югыйсә
Тели күңел сынмавын!
Тели күңел кичәргә
Язмышларның сынавын.

...Янында нәни улы.
Йөрәк кенә... яна шул.
Сыңар канат сыман ла
Куендагы җанашы.

Бу күз яшьле йокысыз
Төн үтәр дә —
Яктырыр...
Инде ничә көн була —
Сәрхуш ире кайтмады...

Битләреңә кагылмас
Корым кебек кара төн.
Җилләр узсын түреңә,
Сыңар булгач канатың!

...Кортлы алма коела
Җәй башында бакчада.
Ятсынма, җил, уз түрдән,
Уз түрдән, җил, ятсынма...

* * *

Әй коела яңгыр, әй коела...
Күк төкәнмәс болытка ябынган.
Бу җанга күптән вакыт юкса
Бушанырга тамчылар шавыннан.
Бу җанга инде күптән вакыт ла
Кояш нурларыннан ямь табарга.
Син әйт аңарга:
— Оныттым, — диген, — яңгырлы көннәрне.
Яңгырлы көннәрдә әйт аңарга.
Син әйт аңарга!
Мин дә оныттым —
Бу көннәр әмма
Кояшлы килеш тә сөйкемсез лә.
Оныттым да, көннәр упкынында —
Үткәнемдә калды синең эзләр.
Әй коела яңгыр, әй коела...
Әй коела яңгыр, әй коела...
Калсак та яңгырда без ант саклап,
Оныттым, дип әйтүе генә,
Әйтүе генә ул, әй, ансат ла.
Әй коела яңгыр, әй коела...

* * *

Гамьсез-гафил буын! Тик син генә
Шуппы афәтләргә тарыма!
Яра калды, яра...
Тама каны
Туган җирнең җешшек карына.

# Кышкы юлда очрашу

— ...Бир кулыңны!
Салкын бит — туңгансың...
Сыкы сарган шомырт агачын...
— Язлар гына белә ул шомыртка
Ничек итеп җылы саласын!

— Салкыннарны карга салып таптыйк
Һәм язларга атлыйк бергәләп!
— Түзәрсеңме, салкын карлар әгәр
Йөрәгеңне алса телгәләп?

— Сөюем дөрли ут ташкындай...
— Йөрәгеңнән калсын күмер тик!
— Бир кулың! Сөюем — сүнеп барган
Тәмәке төпчеге түгел бит!

— Түгелде инде сабыр савытым...
Төшмә юлыма — кит, китче, дим!
— ...
...Ак карда калды,
Ак карда калды
Тапталган тәмәке төпчеге...

# Су кызы

(*Җыр*)

Сер бирми көзнең
Яңгырларына —
Су кызы чыга
Яңгырлы төндә
Ялгызы гына
Идел ярына.

Нигә син ялгыз,
Нигә, су кызы?
Күңелсездер бит
Сиңа ялгызы.

Нигә син болай,
Нигә бик моңлы?
Серләрең булса,
Әйтче, су кызы!

Су кызы күзли
Ерак-еракны.
Ул көтә һаман
Күп гасыр элек
Еракка киткән
Серле корабны.

# Әбиләр чуагы

Берән-сәрән
сары
яфрак...
Гамь бөркелә җир-судан.
Әбиләр чуагы — дәрте
Ташлап киткән ир сыман.

Берән-сәрән
сары
яфрак —
Толымдагы чал сыман.
Тиздән көз җиле: «Инде кыш
Җитте», — диеп чаң сугар.

Берән-сәрән
сары
яфрак,
Чияләрдә — ак күлмәк.
Кырау инәр чакка да бит
Айлап түгел, аһ, көнләп...

Берән-сәрән
сары
яфрак —
Рәссам фасыл гел эштә.
Кырау инәгәч кирәкми шул
Алтын белән көмеш тә.

Берән-сәрән
сары
яфрак...
Фани дөнья тар сыман.
Фани дөнья сөелмичә
Нәүмиз калган яр сыман.

Берән-сәрән
                сары
                яфрак...
Берән-сәрән, гел сыңар.
— Соң, соң, соң, — дип тибә Кояш,
Яшел төсен кем сонар?!

Берән-сәрән
                сары
                яфрак —
Көз арбасы кузгалсын!
Әй кинәнер бу җан, килгәч
Чиксез киңлек көздән соң.

.......................................

Беркайчан да соң булмыйдыр —
Офтанмагыз, яфраклар!
Җылы сөяк сындырмыйдыр,
Ә салкыннан... яр саклар!

## Таң яңгыры

Өлгергәнбез икән кай арада
Таң яңгырына чыланырга?
Чәчәккә бөреләнгән алмагач та
Сусаган бүген бу яңгырга.

Бер чәчәккә бөреләнгән алмагач
Елга ике чәчәк атмастыр...
Кайгыларың шактый —
шатлыкларга
Алмаштыр аларны, алмаштыр!

Юкка гынамыни әллә әнә,
Юл күрсәтеп таңга, төн яна!
Таң яңгырыдай татлы дәва бар,
Бар дәва бар, җаный, дөньяда!

«Тияр, — диеп, — чәчәкләргә салкын», —
Кайгырма син, җаный, кайгырма!
Сусауларын баскан алмагач та
Рәхмәт укый әнә яңгырга.

## Көмеш чатыр

...Тыңлама тамчылар сәгатен —
Бер юкка тып та тып саныйлар.
Бу назлы язгы җил бары тик,
Бары тик мин киткәч зар елар.

Тыңлама тамчылар сәгатен —
Бер юкка тып та тып саныйлар.
Бу сабыр көзге җил бары тик,
Бары тик син киткәч зар елар.

Тыңласаң тамчылар сәгатен,
Тыңла син —
Тик аннан ни мәгънә?!
Бу язда, бу көздә барыбер
Мин Мәҗнүн бит инде,
Син — Ләйлә!

Бу язда, бу көздә барыбер
Тамчылар сулышы яңгырар!
Бу язда, бу көздә тик безгә
Дип кенә яварлар яңгырлар.

Мең чакрымнан мең чакрымгача
Очканбыз ак көмеш чатырда! —
Ләззәти һәм серле бер аһәң
Чакырган еraктан, чакырган!

Бу көмеш чатырда без икәү,
Без икәү — бер икән, без икән.
Дәрьяда тибрәнер мизгелне
Саный аң, сизә җан, төзи тән.

Тик безгә дип кенә китергән
Бу төндә җәйге җил яңгырны.
Бу төндә телгәләп мең кабат
Күбәләк канатын яндырды.

Тик безгә дип кенә килде ул —
Дәрьяда тибрәнер мизгелләр!
Ак көмеш чатырда шатланыш,
Сокланыш көлделәр көзгеләр.

Һич сүнмәс бу яңгыр...
Сүнмәсен!
Дөрләсен бу яңгыр, дөрләсен!
Бер ярсыз дәрья-су мең елдан
Тибрәтер мәңгегә безне дә...

# Көзге гозер

*...гә*

Яфракларны ташла утка —
Яндыр, яндыр барын да!
Булма юләр —
Сүнәр юкса
Көзнең яңгырларында.

Яфракларны ташла утка —
Бөре шыткан чак түгел.
Бөре шыткан чакларында
Котсыз кырау чакты гел...

Яфракларны ташла утка —
Ятлар йөрмәсен таптап.
Калсын әле көзге учак
Безнең серләрне саклап.

Яфракларны ташла утка —
Көзге җилгә карама!
Яфрак түгел, безнең хакта
Мин язган хатлар алар.

Ташла утка яфракларны —
Мин язган хатлар алар!
Яфрак-хатның
Нахак-хагын
Ялкын үзе аралар.

# Серле аһәң

*АРГ*

Оныт! —
Онытма! —
Оныт! —
Онытма! —
Нокта куеп төнге тынлыкка
Теркелдиләр сәгать телләре...

Унбиш ел инде йокы бирми
Төннәр буе серле бу аһәң.
Унбиш ел инде интегәм мин
Мәгънә эзләп синсез яшәүдән.

Бүген дә бердәнбер туганым
Яңа туган моңсу ай гына.
Кичалмам — үләрмен, әгәр дә
Сала калсам сине кайгыга.

Көн белән Төн шикелле без дә,
Без дә бер күрергә тилмереп
Кичәрбез микән, шулай язгач,
Таң сызыгын көтеп, тилереп?

Янә унбиш елдан (кем белә?)
Кавыштырыр әле безне ул —
Көн белән Төн арасындагы
Тар гына алсу таң сызыгы.

...Ишетмәскә серле аһәңне! —
Тушлыйм бар булмыш кодрәтемне.
Сак белән Сок шикелледер шул:
Кавышмаслар Көн вә Төн мәңге...

Оныт! —
Онытма! —
Оныт! —
Онытма! —
Нокта куеп төнге тынлыкка
Теркелдиләр сәгать телләре...

# Көзге халәт

> Күзләреңне зәңгәр томан сарыр,
> Иделләрдән күзең алмасаң...

Дымлы көзләр житте —
Дымлы күзләр...
Томан сарган Идел буйларын.
Йөрисеңдер син дә аргы ярда,
Уйларыңның тыңлап юк-барын!

Йөрисеңдер син дә, ерак ярга
Дулкыннарны кире озатып.
Йөрисеңдер син дә, минем сыман,
Еракгагы ярга күз атып.

Кавыштырмас ярны ярга дулкын,
Дәвам итәр Идел йоклавын.
Дымлы күзең йомып елмай да син,
Уйларыңның ташла юк-барын.

Дымлы күзең йомып елмай да син,
Оныт инде, оныт һәммәсен!
Тик онытма, зинһар, бергә кичкән
Мизгелләрнең асыл мәгънәсен.

Җансыз суда үрсәләнгән ялгыз
Сары яфрак зарын тыңлама!
Дымлы күзләр аша дымлы көздә
Дөнья үзе тоташ дымлана.

...Дымлы көзләр, күзләр — бар да дымда,
Иләсләнгән мәллә бу дөнья?
Тыпырчына дымлы ярлар анда,
Әйләнергә теләп бөтенгә.

Дымлы күзләр, көзләр — һаман дымда.
Киптералмас барын мең кояш!
Исе дә китми син елмайганга —
Башкаларга килә бүген яз!

## Зилзилә

Җир җиләге җыйган чакта,
Зилзиләгә тарыдык.
Калдык инде, һай, калдык ла
Кавышмаслык яр булып.

Кавыштырды җир җиләге,
Аерды ла зилзилә.
Без кавышкан аланнарда
Исә хәзер җил генә.

Ул җәйләрнең сандугачы —
Сайрамастыр, һай, ул кош.
Инде юллар безнең хәзер
Аймылыш та аймылыш.

Җир җиләкле җәйләрдә лә
Зилзиләгә тарыдык.
Җәйнең хәзер — җиләкләре,
Кышның исә кары юк.

## Сер

Бер сер туа уналтыда,
Уйларыңны тузгытып.
Бер сер туа күңелеңдә,
Татлы газап кузгатып.

Сала хәтта салкынга ул,
Аннан ташлый ялкынга.
Ул — көмеш тә,
Ул — алтын да!
...Сер туа уналтыда!

# Соңгы хат

*Әфганстанда һәлак булган татар
егетләренең якты истәлегенә*

— Сусадыңмы? — диеп язгансың...
Ялый безне ялкын камчысы.
Уттай иреннәргә нибары
Тама, ява кургаш тамчысы.

— Сәламнәрең сирәк, — дигәнсең...
Тиште ядрә гомер җилкәнен.
Җыры булыр соңгы сәламем
Канатлары парсыз җилкәйнең.

— Ничек анда? — диеп сорама,
И кадерлем, сөю-сагышым.
Ишеткәнең синең бармы соң
Җәрәхәтле болыт тавышын?

— Йолдызым һич сүнмәс! — дисеңме? —
Юк инде ул йолдыз — бел шуны!
Бугазында калды күкләрнең
Һәлак
        булган
                йолдыз
                        кылчыгы...

# Солдатка алынганда

...Яфрак койган бу тупыллардан да
Моңсу-ямансу бүген юк сыман.
Тупылларга сарылган сылулар
Юксынырлар безне, юксынырлар.

Кемнәр, безгә чират җиткәч кенә,
Яуны яуга илдә ялгаган?!
Буламыни тагын Ватан хисен?
Инде туйган бетмәс ялганнан...

Көтә булыр безне әллә кайда —
Билгесезлектә — «дед»лар, «фазан»нар...
Төшкә керер тиздән, төшкә керер
Сөембикәле газиз Казаннар.

Безнең кайтканны көтәр матчада
Ак күмәчнең тешләнгән телеме.
Әнкәйләрнең чәчендә ни бу, ни —
Язмышлар яккан учак көлеме?

...Сагыну дымы сакланыр микән
Без сөйгәннәрнең алсу иренендә?..
Алда — юллар... Киттек әле.
Ә-ә-нә, —
Кыркыганнар бит чәчен җирнең дә.

## 1989 елның феврале. Кайту

Мәңгегәме артта калды
Саланганың салкын кары?
Алда — Термез.
Көтә инде
Урыс кышы салкыннары...

Егылырбыз кайтып илгә,
Сөйгәннәрнең кочагына.
Көйгән гөлләр бөреләнер
Шунда гына...
Шул чагында!

«Кадалышлар гына инде
Китсен лә бу дөньясы, — дип, —
Үлә-нитә калсак әгәр,
Чыгар безгә
Кем ясин?» — дип.

Тәмуг тавын кичкән чакта
Пышылдаган утлы бугаз
Йотлыгышлар эчәр хәмер —
Әмма ул чак
Онытылмас.
Оныттырмас!

Ярлыкармы туган җирем?
Нинди чалым эзләр йөздән?
Имәнеч төшләр йөдәтер —
Шәһитләр үч алыр бездән.

БМПлар, этләр кебек,
Канлы гәүдәмне ботарлар.
Ак карга саркылыр каным...
Эреп бетәрме бу карлар?

Төшемдә түгел, өнемдә
Каргыш төшәр мең батманлык...
Тагын кем безне каһәрләр:
«Кулың канга баткан», — диеп?..

## Әфган кызы

Пәрәнҗәңне япчы, шашам бит,
Ник ачтың аны, туташ?
Горур тауның кыргый ләләсе,
Аһ, бу йөз, бу күз, бу каш!

Карашыңны тоям үземдә,
Күңелләрем сызыла...
Охшагансың бит син шулкадәр
Безнең авыл кызына.

# Күренеш

Көмеш айлы биек манара,
Килә моңлы азан тавышы.
Агачлар яба пәрәнҗәсен,
Дога кыла ялгыз тау кошы...

Ак еландай сукмак каршына
Таш дуваллар калка тын калып.
Комнар туза иркен далада —
Җил актара Шәрык китабын.

Җил эзли киташның ак битен —
Чал чәчле вакытка — язарга!
Тын калып кылганнар чайкала,
Чайкала борынгы мазарда*...

«Һәр мизгел кадерен дөньяның
Бел!» — диеп, колакка кем дәшә?!
Кылдан да нәзек ызаннарда
Оҗмах белән тәмуг янәшә.

Ызаннарда калсаң егылып,
Чыгар монда сиңа кем ясин...
Сусау баса җанны богаулап,
Кадалышлар китсен дөньясы!

Кояш-шаһның серле төбәге...
Дөньяның ла соң бу кай ягы?!
Кайсы галәмнәргә юнәлә
Мең өркәчле таулар кәрваны?!

---

* М а з а р — зират.





## IV

Инде янә бер мизгел һәм...
Күзләр чагыла төсләрдән:
Алтын алма, кызыл алма —
Күр! —
Кызылтүшләр, песнәкләр.

## Кем төшенә ни керә?

Гөмбә төшенә яңгыр керә.
Тавык төшенә тары керә.
Инеш төшенә Идел керә.
Бабай төшенә дару керә...

Айдар төшенә ни керәме? —
Ул төшендә әнисен күрә!

## Язгы шатлык

Йокысын алды
Ялгыз шомыртның,
Гөрләп, яңгырап,
Назлы ямь булып,
Кояшлы язның
Тәүге яңгыры!

Күзләрен ачты
Нәни бөреләр.
Әй шатландылар,
Әй көлештеләр.

Тәмләп эчтеләр
Ширбәт-тамчыны.
Гөлләргә күчте
Алар шатлыгы.

## Кичке манзара

Ерактагы офыкта
Ут булган дисәм урман,
Агачларның иңенә
Кояш төшеп утырган.

## Кояш йоклаганда

Ни булган бу кояшка —
Йоклавына чама юк.
Мендәренә тышлык чигә
Көмеш инә-самолет.

## Томан

Иртә таңнан
Бу ни булган:
Тирә-якта —
Ап-ак томан.

Яңа сауган
Җылы сөтнең
Тәмле исе
Килә аннан.

# Җил тегермәне

...Тегермәнгә типкәли
Суык кышның ак аты.
Туңа бугай тегермән —
Шы-гыр-р-дый тик канаты.

Заманында тегермән
Олау-олау он тарткан.
Тарта-тарта он
Аның
Җегәре дә ун арткан...

— Салкыннары ү-ү-үтә
Чарыгымның төбеннән...
— Кар көртенә төренеп
Йокласаңчы, тегермән!

— Он тәме килә, — диеп, —
Әле яуган ак кардан, —
Сагышланма, тегермән,
Арынсаңчы аһ-зардан!

Көтеп ал син җәйләрең,
(Бабай кебек сабыр бул!) —
Һәм әйләнер, әйләнер
Синең саллы чарыгың...

Җитсен генә җәйләре —
Бабам көйләп җибәрер...
Җибәрер дә — тегермән
Җилдереп җигәр җилне —
Җәйнең житез җәйрәнен!

## Кем житез?

Һәй!
Колыным белән икәүләп
Инләдек тә буйладык
Болыннарын, үрләрен!
Тик
Ашыкмасын гына берүк
Каникулның көннәре.
Һәй!
Җилдереп уздык җилне дә —
Җәйнең житез җәйрәнен!
Тик...
Бездән өлгер, җилдән житез
Каникулның көннәре...
Их!
Шундый көндә, ашыкмыйча,
Мең чәчәкле болында,
Соң,
Каникулга, безнең кебек,
Черем итсә ни була?!

## Көзге елмаю

Сизми дә калганбыз, әй:
Җәйнең соңгы көннәре...
Салкын җилгә сер бирми
Җирнең сылу гөлләре.

Без йөрибез урамда,
Күзебез бәйләнгәнче.
Елмаер әле гөлләр,
Көмеш чык тамчылары
Кырауга әйләнгәнче...

## Алмагач чәчәк ата!

...Уйламый да, ичмасам,
Уянган диеп абый...
Көпә-көндез — күр инде! —
Энекәш йоклап ка-ры-ый!

— Ач күзеңне, тор әйдә! —
Тәпи-тәпи син атла!
Өй каршында — бакчада —
Алмагач чәчәк ата!

«Алмаларым!» — ди безгә
Әти белән әни дә.
Шулай булгач, чәчәген,
Чәчәген күрик әйдә!

## Глобуска карап уйлану

Бар Җир шары — кочагымда,
Уч төбемдә — кыйтгалар!
Ул тауларның, елгаларның,
Диңгезләрнең, илләрнең
Исәбе юк — күп алар!

Телисезме, кирәк икән,
Бармак белән бөяп куям
Иң озын Нил елгасын?!
Юк-юк, зинһар, ага бирсен! —
Кабул итсен Җир-әнкәбез
Йөрәгемнең җылысын!

# Кышның соңгы төсләре

Ап-ак чыршы, ап-ак тынлык,
Ап-ак кар, ап-ак болытлар...
Төсләренең калганнарын
Рәссам Кыш, ахры, оныткан.

Калган төсләргә буярга
Бабай Кыш, әйе, оныткан...
Исенә төшерергә дип,
Оныгы Яз килә арттан.

Бабасының көен көйләп,
Оныгы Яз килә арттан!
— Әй, бабакай, — дим, — пумалаң
Нигә әле карга баткан?!

...Кинәт кар тауның артыннан
Калкып-балкып чыкты Кояш! —
Төсләр белән тулды җиһан,
Аның нурына коенгач.

Инде янә бер мизгел һәм...
Күзләр чагыла төсләрдән:
Алтын алма, кызыл алма —
Күр! —
Кызылтүшләр, песнәкләр!

# Сакаллы су

Әй көлә ул, әй көлә,
Әй көлә ул шар ярып.
Кем дисезме, кем булсын —
Сакаллы су-шарлавык!

Манзаралы шарлавык —
Анда китә күренеп,
Монда китә күренеп,
Һәркайда ул — ак күбек.

Алтын нурларын Кояш,
Кармак кыллары сыман,
Берәм-берәм бик ишләп,
Сакаллы суга сузган.

Абыем болай диде:
— Безнең бу — Ниагара!
Ни бар анда дисеңме —
Көмеш балык бар анда! —

...Шарлавыкның сакалы —
Тарак-тарак тармаклы.
Алтын нурдан уздырып
Салдык шунда кармакны.

Кармакларны карадык
Бер алып та бер салып.
Эләкмәде һич юкта
Бармак кадәрле балык.

— Бу инешне «сугара»
Сабын заводы гына...
Сакаллы сабый... — диде
Сакаллы су абыйга.

# Куян куу

Ап-ак йомры куян чыккан
Бәрәңге бакчасына.
Сорау арты ява сорау
Айдарның бабасына:

— Сурәттәге ул куянны
Төлке куа иде бит.
Юк төлкесе бу куянның,
«Төлкеле ул» диден бит...

— Бу заманда, — ди бабасы, —
Ни куяны, төлкесе...
Дөньясы да, улым, аның
Күңелсез, әй, күңелсез.
Адәмнәре үзе хәзер —
Йә куян да, йә төлке.
Сүрән
    сурәт
        сыман
            сүнә
Фанилыкның ямь-күрке.

Мут күзле җитез төлкегә
Куян тоту читенме?
Уңы-сулы дөнья куа
Куян куган шикелле.

...Төлке булып уянды да
Көзге яфрак бураны,
Куа, куа яфрак-төлке,
Әй куа ул куянны!

Ә Айдаргамы? Айдарга —
Көлке дисәң дә көлке:
Ак куянны тоталмады
Алтын койрыклы төлке...

## Кое казыйм

Казан кадәр Казанда
(Әле килде уема!)
Нигә икән калмаган
Чишмә түгел, кое да?!

Килгән икән уема —
Көрәгемне алдым да,
Үзебезнең комлыкта
Тотындым казырга!

Алай ансат-тиз генә
Телдән чыга сүз генә...
Коелы булыйм дисәң —
Казыйсы бар — түз генә...

Табасы бар бурасын,
Куясы бар чыгырын.
Шуннан соңмы? — Шуннан соң —
Чиләк белән чылбырын!

Кое казу — тиз генә
Була торган эш түгел,
Казыйсы бар — түз генә...
Тәмле суын эчәргә
Чакырырмын сезне дә!

## Ындыр табагында

Алтын арыш бөртекләре,
Алтын бодай бөртекләре,
Чын әгәр, чакматаштыр:
Кабызырга әзер алар —
Сүнә калса, Кояшны!

## Иртә

Кузгалаклы болында
Тынгы белми кич-иртә,
Кем ул анда, кем икән
Елап ята бишектә?

Уч төбендә Кузгалак
Чык тамчысын биетә:
Әле тәпи китәргә
Бик иртә, ди, бик иртә...

Каян килгән шаян Җил —
Бишек бавын селкетә.
Болындашлар һәммәсе
Һаман көтә...
Ни көтә?

...Кемне димсез? — Айдарны
Яланаяклы Иртә,
Кулыннан тотып, әнә
Болын буйлатып йөртә!

## Табышмак

Көмеш канат,
Көмеш томшык.
Әй сайрый бер
Нәни кошчык.

Талпынып да,
Кулың сузсаң,
Шундук очып
Китәр сыман.

*(Чишмә)*

# Эчтәлек

## I


Ватан .......... 7
Караңгылык .......... 8
«Урыс каены, диләр...» .......... 9
Бәһа .......... 10
«Базар читендә бер карт...» .......... 10
Хәер сорануча .......... 10
Капка төбендә .......... 11
Ирек .......... 11
Бер ачыш .......... 11
Китап .......... 12
Ишелгән мич .......... 12
Татар тормышы .......... 13
Фәрештә .......... 13
Мөһаҗир .......... 14
Нократ .......... 15
Дусай җыры .......... 16


## II


Кояшлы төн .......... 19
Кышкы халәт .......... 20
Буранда .......... 22
Биеклек .......... 23
Ят күл .......... 23
Мамык дивар .......... 24
Матурлык .......... 25
Энемә .......... 26
Күзгә манзара .......... 28
«Ачыргаланып аваз салды...» .......... 28
Ташландык йорт .......... 29

Ялгыз яфрак ........................................ 30
Яшел яфрак җыры ........................................ 31
«...Әллә ниләр кирәк сыман...» ........................................ 32
Түрә — түбә ........................................ 32
Акча колы ........................................ 32
Бәллүр көймә ........................................ 33
Замана ........................................ 33
Уян! ........................................ 34
«...Яратылуын яратылганбыз...» ........................................ 34
«Юмарт» язмыш ........................................ 35
Качкын ........................................ 36

## III

Ашкыныр чак ........................................ 39
Телефон ........................................ 39
Миләүшә ........................................ 40
Мәхәббәтем ........................................ 40
Әллә ничек кенә... ........................................ 41
«Минем шатлык синең шатлык булалмады...» ........................................ 41
Талчыбык ........................................ 42
Кышкы сөю ........................................ 43
Төнге этюд ........................................ 43
«Көз — кызлар күңеле төсле...» ........................................ 43
Юрау ........................................ 44
«...Ашыктыра алсу җиләк...» ........................................ 45
Төнлә су керүче кызга ........................................ 46
Сыңар канат ........................................ 47
«Әй коела яңгыр, әй коела...» ........................................ 49
«Гамьсез-гафил буын...» ........................................ 49
Кышкы юлда очрашу ........................................ 50
Су кызы ........................................ 51
Әбиләр чуагы ........................................ 52
Таң яңгыры ........................................ 54
Көмеш чатыр ........................................ 54
Көзге гозер ........................................ 56
Серле аһәң ........................................ 57
Көзге халәт ........................................ 58
Зилзилә ........................................ 59
Сер ........................................ 59
Соңгы хат ........................................ 60
Солдатка алынганда ........................................ 61
1989 елның феврале. Кайту ........................................ 62
Әфган кызы ........................................ 63
Күренеш ........................................ 64

## IV

Кем төшенә ни керә? ........ 67
Язгы шатлык ........ 67
Кичке манзара ........ 68
Кояш йоклаганда ........ 68
Томан ........ 68
Җил тегермәне ........ 69
Кем җитез? ........ 70
Күзге елмаю ........ 70
Алмагач чәчәк ата! ........ 71
Глобуска карап уйлану ........ 71
Кышның соңгы төсләре ........ 72
Сакаллы су ........ 73
Куян куу ........ 74
Кое казыйм ........ 75
Ындыр табагында ........ 75
Иртә ........ 76
Табышмак ........ 76

Литературно-художественное издание

Марат Закир
(Закиров Марат Халилович)

# Солнечная ночь

(на татарском языке)

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *Х.Н.Латыйпов*, тышлык рәссамы *В.Е.Булатов*
*Н.Нәккаш (Исмәгыйлев)* туграләры
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы
*В.А.Савельева*
Корректоры *Л.З.Шиһапова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның
6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 09.06.2005.
Форматы 70×90 $^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «Times New Roman» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 2,93 + форз. 0,15.
Шартлы буяу-оттиск 3,81. Нәшер-хисап табагы 2,71 + форз. 0,24.
Тиражы 2000. Заказ А-437.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

ААЖ «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы
дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Êàçàí, Äåêàáðèñòîëàð óð., 2.